Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

13 сентябрь 2019 ел №320

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итү турында

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу сәбәпле, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 37 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 26 маддәсе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының 29, 46 маддәләренә таянып,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

2. Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 23 сентябрендәге №6 «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итү турында»гы карарына(Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советның 2019 елның 24 июне №296 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Конкурс комиссиясенә 2019 елның 19 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләрен, кандидатлар турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советына тәгъдим итәргә».

3. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында»(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район башлыгы Т.Д. Нагуманов